**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2017 ел, 6 март

№ 128

г. Казань

2017 елга Халык өстенлекләре Реестрын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы норматив хокук актларын һәм муниципаль хокук актларын кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыруның тәртибе турында» 2007 ел, 19 нчы март, 90 нчы номерлы карарын тормышка ашыру максатларында, 2016 елда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган 2017 елга Халык өстенлекләре Реестрын расларга (алга таба – Реестр).

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына:

Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча чараларны Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләнелүче дәүләт программаларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук әлеге чараларны тормышка ашыруны мониторинглауны контрольдә тоту буенча җаваплы затларны боерык белән билгеләргә;

2017 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча башкарылган эш турында мәгълүматны, халык өстенлекләрендәге төп проблемалар исемлеге кисемендә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә тапшырырга.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнары белән бергә Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эше барышын һәм нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары А.В.Песошинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 6 март, 128 нче
карары белән расланды

**2017 елга халык өстенлекләре реестры**

| Т/с | Өстенлек исеме | Өстенлекне билгеләгән халык өлеше, процентлар | Төп мәсьәләләр исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Бәяләр һәм тарифлар үсүне тыю, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сыйфатын күтәрү | 48,6 | даими үсүче бәяләр һәм тарифлар;<br>икътисадый нигезләнмәгән бәяләр һәм тарифлар;<br>бәясе һәм сыйфаты туры килми торган товарлар һәм хезмәтләр;<br>торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләре югары булган йортның гомуми ихтыяҗлары;<br>дәүләт ягыннан контрольнең булмаган торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре эшчәнлеге |
| 2. | Эшсезлек дәрәҗәсе кимү | 38,4 | җитәрлек санда булмаган югары хезмәт хакы булган эш урыннары;<br>үсеш алмаган производство;<br>кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә хакимият органнары игътибары җитмәү |
| 3. | Халыкның керем дәрәҗәсен күтәрү | 34,1 | эш хаклары, пенсияләр һәм пособиеләрнең түбән дәрәҗәсе;<br>халык керемнәренең пропорциональ булмаганча бүленүе;<br>җитәрлек санда булмаган югары хезмәт хакы булган эш урыннары;<br>эш хакы түләүне тоткарлау;<br>социаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем алырлык булмавы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Наркоманлыкка һәм эчкечелеккә каршы тору | 26,4 | алкогольне күп куллануның һәм наркотикларны медицина кушмаганча куллануның тискәре нәтиҗәләре турында халыкка бирелгән мәгълүматның түбән нәтиҗәлелеге;<br>алкогольнең халык өчен һәркем алырлык булуы;<br>наркотик чараларны кулланган һәм тараткан өчен җәзалауларның тиешенчә катгый булмаган системасы;<br>эчкечелектән һәм наркоманлыктан мәҗбүри дәвалау системасы булмау |
| 5. | Ришвәтчелек һәм коррупциягә каршы тору | 23,7 | хакимият органнарында коррупцияне кисәтү буенча нәтиҗәле эшнең җитәрлек булмавы;<br>гражданнарның түбән хокук культурасы;<br>хокук саклау органнарына ышанычның түбән дәрәҗәсе;<br>җитәрлек дәрәҗәдә катгый булмаган ришвәтчелек өчен җәзалау системасы |

______________________